Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

«08» апрель 2025 ел № 11

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2025 елның 08 апрель түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 28 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2024 елның 28 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне»;

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 2659 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 1455 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 1332 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 118 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карар кабул ителгән дип танырга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге составына керүче Бәтке авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2024 елның 28 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Бәтке авылында гражданнар җыены карарына:

«- су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне»;

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru), Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүматы порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Бәтке авыл җирлеге Башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге советы рәисе,
Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы
Бәтке авыл җирлеге Башлыгы В.А.Валиева